ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕЯКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, 1, с.Большие Яки,
Зеленодольский район, 422524

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ ЖӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Мэктэп ур., 1, Олы Яке авылы,
Зеленодольск р., 422524

Тел.факс: (84371) 6-60-44. E-mail: Bkn.Zel@tatar.ru, www.zelenodolsk.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
КАРАР

**«7» ноябрь 2022 ел** **№ 40**

«2021 елның 20 январендәге 1 нче номерлы карары белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибенә үзгәрешләр кертү турында»

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге Федераль закон, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131-ФЗ ноомерлы Татарстан Республикасы Законы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 28.07.2004 №45-ТРЗ (10.09.2020 ред), Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының “Олы Җәке авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Олы Җәке авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 нче елның 20 нче январендәге 1 нче номер белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибенең 3 пунктына үзгәрешләр кертергә, аны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Халык җыены карары белән муниципаль берәмлектә (торак йорт), яисә аның территориясе өлешендә) яшәүчеләрнең гомуми саны 30 проценттан артып китә алмаган гражданнарның аерым категориясе билгеләнә, алар өчен түләүләр күләме кимергә мөмкин.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Олы Җәке авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: Олы Яке авылы, Мәктәп урамы, 1 йорт (администрация бинасы), Олы Яке авылы, Мәктәп урамы, 1а йорт (зур Җәке КФҮ бинасы), Каратмән авылы Клуб урамы, 23 нче йорт (Каратмән авыл клубы бинасы), Уразла авылы Паратская урамы, 138П (Уразлы авыл клубы бинасы).

4.Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

Җитәкче : Ф.А.Фәйзуллина